ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«10» август 2026 ел № 180

**Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында**

Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләрен хәл итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителә торган затларны ресоциальләштерү эшчәнлеген оештыру турында” 2019 елның 29 июлендәге 631 номерлы карары нигезендә **КАРАР БИРӘМ**:

1. Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия составын (1 нче кушымта).

- Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмәне (2 нче кушымта);

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясенә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча чаралар планын эшләргә һәм расларга.

4. Арча муниципаль районы башлыгының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында 2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы үзгәрешләр белән) 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы үзгәрешләр белән) 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү

мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында" 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы үзгәрешләр белән) 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы;

- "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының "Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында" 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы үзгәрешләр белән) 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы;

- "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының "Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында" 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы үзгәрешләр белән) 2023 елның 11 августындагы 95 номерлы;

- "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының "Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында" 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында" (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 95 номерлы үзгәрешләр белән) 2023 елның 6 октябрендәге 121 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 95 номерлы, 2023 елның 6 октябрендәге 121 номерлы үзгәрешләр белән) 2024 елның 31 маендагы 61 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 95 номерлы, 2023 елның 6 октябрендәге 121 номерлы, 2024 елның 31 маендагы 61 номерлы үзгәрешләр белән) 2025 елның 20 августындагы 119 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 95 номерлы, 2023 елның 6 октябрендәге 121 номерлы, 2024 елның 31 маендагы 61 номерлы, 2025 елның 20 августындагы 119 номерлы үзгәрешләр белән) 2025 елның 22 октябрендәге 162 номерлы;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгының “Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия төзү турында” 2019 елның 12 ноябрендәге 142 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” (2020 елның 22 гыйнварындагы 3 номерлы, 2020 елның 21 августындагы 93 номерлы, 2021 елның 16 февралендәге 15 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 190 номерлы, 2023 елның 13 апрелендәге 55 номерлы, 2023 елның 11 августындагы 95 номерлы, 2023 елның 6 октябрендәге 121 номерлы, 2024 елның 31 маендагы 61 номерлы, 2025 елның 20 августындагы 119 номерлы, 2025 елның 22 октябрендәге 162 номерлы үзгәрешләр белән) 2026 елның 28 гыйнварындагы 22 номерлы;

5. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында” (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Арча муниципаль районы башлыгы А.Г. Хисаметдинов

Арча муниципаль районы
башлыгының
“10” август 2026 ел,
№180 карарына
1нче кушымта

**Ирекtән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия СОСТАВЫ**

| | |
|---|---|
| Хисаметдинов Алмаз Гаптрауп улы | - Арча муниципаль районы башлыгы, комиссия рәисе; |
| Шәһмәрданова Рәзилә Габделнур кызы | - Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Габдрахманова Алсу Якуб кызы | - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе баш белгече, комиссия сәркатибе; |

***Комиссия әгъзалары:***

| | |
|---|---|
| Гобәйдллин Айрат Дамир улы | - Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча Эчке эшләр бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әмиров Раушан Марат улы | - “Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе” федераль казна учреждениесенең Арча муниципальара филиалы җитәкчесе (килешү буенча); |
| Хөснетдинова Лилия Салихҗан кызы | - “Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җинаять-башкарма инспекциясе” федераль казна учреждениесенең Арча муниципальара филиалы пробация баш инспекторы (килешү буенча); |
| Идрисов Рифат Илшат улы | - “Арча үзәк район хастаханәсе” дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесы баш табибы (килешү буенча); |
| Муллахмәтов Нияз | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының |

| | |
|---|---|
| Наил улы | “Мәгариф идарәсе” муниципаль учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Әюпов Илфар Илдар улы | - Арча муниципаль районы башкарма комитетының “Мәдәният идарәсе” муниципаль учреждениесе җитәкчесе (килешү буенча); |
| Гыйбадуллина Гөлфия Мансур кызы | - “Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” дәүләт казна учреждениесының Арча районы буенча бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Ибраһимова Динә Мансур кызы | - ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Арча муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге җитәкчесе (килешү буенча); |
| Һидиятуллин Фәнил Фәнис улы | - Арча муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре буенча спорт һәм туризм бүлеге җитәкчесе. |

Арча муниципаль районы
башлыгының
“10” август 2026 ел,
№180 карарына
2нче кушымта

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча муниципаль ведомствоара комиссия турында нигезләмә

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссия (алга таба – Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы каршындагы даими эшләүче координацияләү органы булып тора, ул Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча үзара эшчәнлеген координацияләүне һәм хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итә.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүгә ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы Нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге ресоциализацияләүдә ярдәм күрсәтү күздә тотылган затларның ихтыярый һәм ихтыяр белдерү иреге принципларына нигезләнә.

II. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып тора:

2.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасын үтәгән һәм (яисә) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар булган затларны җәмгыятькә реинтеграцияләү максатларында социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру, шул исәптән:

постпенитенциар озата бару;

һөнәри ориентация һәм хезмәткә яраклашу;

торак һәм көнкүреш төзелеше;

медицина ярдәме күрсәтү;

психологик ярдәм;

югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуга ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген һәм үзара хезмәттәшлеген координацияләүне тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның республика регистрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау.

2.5. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү һәм хезмәттә реинтеграцияләү буенча алып барыла торган эшләр турында җәмәгатьчелеккә хәбәр итү.

## III. Ведомствоара комиссиянең вәкаләтләре

Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Ресоциализациягә ярдәм күрсәтүгә ризалык алган затларның социаль хәлен индивидуаль тәртиптә карый һәм анализлый.

3.2. Законнарда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнарын, граждан җәмгыятенең башка оешмалары һәм институтлары мөмкинлекләрен исәпкә алып, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затны ресоциальләштерүнең индивидуаль программасын эшли. Реабилитация программасында каралган һәр чараны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларны, аларны гамәлгә ашыру срокларын билгели.

3.3. Ресоциальләштерү буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм нәтиҗәлелеген анализлый.

3.4. Түбәндәге очракларда ресоциализацияләүнең индивидуаль программасын гамәлгә ашыруны туктату турында карар кабул итә:

тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешү;

зат даими яшәү урынына Арча муниципаль районыннан читкә киткән очракта (зат Татарстан Республикасы чикләрендә башка муниципаль районга киткән очракта, күрсәтелгән факт турындагы мәгълүмат затка карата булган

материаллар белән бергә Татарстан Республикасы тиешле муниципаль районының ведомствоара комиссиясенә җибәрелә);

ресоциализацияләүгә ярдәм итүдән баш тарту турында зат гаризасы килгәндә;

ресоциализацияләүнең индивидуаль программасын алга таба гамәлгә ашыру мөмкинлеген бетерә торган башка очракларда.

3.5. Арча муниципаль районында кабат (рецидив) җинаятьчелекне профилактикалау мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия хокуклы:

3.6.1. Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, граждан җәмгыятенең башка оешмалары һәм институтлары тарафыннан үтәүгә тәкъдим ителгән карарларны үз компетенциясе чикләрендә кабул итәргә;

3.6.2. Җинаять яисә административ җаваплылыкка китерә торган закон бозу билгеләре ачыкланган очракта гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документлар һәм материаллар җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе чикләрендә хезмәттәшлек итә:

3.7.1. Россия Федерациясе Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча;

3.7.2. Эчке эшләр органнары белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;

индивидуаль профилактика эше уздыру;

хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу.

3.7.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләрнең (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре) түбәндәге мәсьәләләр буенча:

“Дәүләт социаль ярдәме турында 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм “Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында, шул исәптән социаль контракт нигезендә” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;

билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр алучылар белән социаль адаптация үзәкләрендә профилактика эше;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче балигъ булмаганнарны, шулай ук иректән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән

балигъ булмаган гражданнарны социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә социаль адаптацияләү;

хезмәт базары, вакансияләр булу турында мәгълүмат бирү юлы белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителергә әзерләнүче затларны ресоциальләштерүгә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау максатларында һөнәри ориентация буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү, эшкә урнашу, һөнәри белем бирү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган күрсәтелгән категориядәге затларга – эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, эшсез гражданнарны хезмәт базарында социаль адаптацияләү, һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча түләүсез дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән эш бирүчеләрне, эшкә урнаштыручы затларны стимуллаштыру.

3.7.4. Территориаль сәламәтлек саклау идарәсе (булган очракта), сәламәтлек саклау учреждениеләре белән беренчел медицина-санитария ярдәмен оештыру, профилактика һәм диспансер күзәтүе мәсьәләләре буенча;

3.7.5. Дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, граждан җәмгыяте оешмалары, институтлары белән аларның компетенцияләре нигезендә.

## IV. Ведомствоара комиссияне төзү тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

Ведомствоара комиссия рәисе:

Ведомствоара комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә;

хәлиткеч тавыш хокукына ия булып, ведомствоара комиссия утырышларын алып бара;

Ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

Ведомствоара комиссия әгъзаларына үз вәкаләтләре кысаларында йөкләмәләр бирә;

Ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителә торган документларга имза сала;

Ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

Ведомствоара комиссия сәркатибе:

ведомствоара комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен төзи, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җәзаны үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән затның алда торган азат ителүе, аның торагы булуы, хезмәткә сәләте һәм булган белгечлекләре турында мәгълүмат җыюны һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализациягә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кабул итә;

ресоциальләштерү программасының һәр катнашучысына озата бару картасын һәм шәхси эшне рәсмиләштерә, аңа ресоциальләштерүнең индивидуаль программасы чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кертелә;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып ала;

ведомствоара комиссия утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә;

ведомствоара комиссия рәисе йөкләмәләрен, аның утырышлары нәтиҗәләре буенча күрсәткечләрне үтәүне оештыра;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халкына ведомствоара комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәгариф оешмалары вәкилләре (килешү буенча) керергә мөмкин.

4.4. Ведомствоара комиссия составына элек иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциализацияләүдә уңай тәҗрибәсе булган затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Арча районы прокуратурасы вәкиле (килешү буенча) катнашырга хокуклы.

4.6. Ведомствоара комиссия утырышларына Ведомствоара комиссия составына кермәгән дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырылырга мөмкин.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## V. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализациягә ярдәм күрсәтү турында гаризалар кергән саен үткәрелә, ләкин аена бер тапкырдан да сирәгрәк түгел. Кирәк булган очракта ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасы инициативасы буенча (рәис белән килештереп һәм ведомствоара комиссия секретаре тәкъдиме буенча) ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары уздырылырга мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышларын ведомствоара комиссия рәисе алып бара, ә ул булмаганда яисә аның кушуы буенча – ведомствоара комиссия рәисе урынбасары.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында ресоциализацияләүдә ярдәм күрсәтү турында гариза алган затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашуы максатка ярашлы дип танылган башка затларга утырыш көненә кимендә бер тәүлек кала хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында Арча районы прокурорына хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы, анда аның составының яртысыннан артыгы катнашса, тулы хокуклы була.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерында була һәм ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия булалар.

5.9. Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затның теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча уздырыла.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары комиссия утырышында каралган мәсьәләләр турындагы белешмәләрне күрсәтелгән мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка таратырга хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турындагы белешмәләрне тараткан өчен ведомствоара комиссия әгъзалары законнар нигезендә җаваплы булалар.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән массакүләм мәгълүмат чараларына шәхси белешмәләрне күрсәтмичә генә тиешле мәгълүмат бирү рөхсәт ителә.